**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Исполнительный комитет
Сарлинского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Центральная, д.68А, с. Сарлы,
423315
Тел. 365-34

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Азнакай муниципаль районы
Сарлы авыл җирлеге
башкарма комитеты

Үзәк урам, 68А,
Сарлы авылы, 423315
Тел. 365-34

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23 сентябрь 2019 ел №29

Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22, 56 статьялары, 24.03.2004 ел №23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, карар чыгарам:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Сез 2020 елда Сарлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә, 2 Төркем инвалидларыннан 150 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Сарлы, Бүләк, Сөендек авылларында кышын юлларны кардан чистарту;
- Сарлы авыл җирлегендә "Сабантуй" бәйрәмен оештыру һәм үткәрү;
- Сарлы, Бүләк, Сөендек авылларында урам исемнәре язылган табличкалар ясау;
- янгын депосы өчен җир кишәрлеген рәсмиләштерү;
- Сарлы авылында янгын сүндерү автомобиле өчен запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу, янгын сүндерү автомобиле йөртүчегә хезмәт хакы түләү;
- Сарлы, Бүләк, Сөендек авылларында балалар уен мәйданчыгын сатып алу, урнаштыру;

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карар түбәндәге чаралар аша халыкка игълан ителергә тиеш:

- Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Сарлы авылы, Үзәк ур., 68А йорт, Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Сөендек авылы, Яшел ур., 34 йорт, Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Бүләк авылы, Үзәк ур., 26Б йорт адреслары буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында;
- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,
- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Башлык М.Р.Шәрипов